| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬКЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛКИ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 17 декабре 462№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 елның 15 ноябрендәге «2023 елда Әлки муниципаль
районы гомуми белем бирү оешмаларында
укучыларның кайнар тукlануын оештыру турында»
421 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 1 октябрендәге «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1212 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге «2023 елда Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның кайнар тукlануын оештыру турында» 421 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләрнең балалары, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына).»

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче: Р.Х.Морадымов

Захарова Н.П.